# Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнар җыены

КАРАР

20 ноябрь 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Бәзәкә авыл
җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 10 ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә, гражданнар җыенының 2025 елның 20 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә: сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 469 катнашучы кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 289 кеше; тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «хуплый» позициясе өчен гражданнар җыенында 289 катнашучы тавыш бирде, «каршы» позициясе өчен 0 тавыш. Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. “2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан Сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән 50%ка киметеп 500 сум күләмендә, ә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?” дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;(илтеп җиткереп вак таш сатып алу, вак ташны тигезләү, асфальт валчыклары сатып алу, Бәзәкә авылындагы юлларны кардан чистарту, узган елларның калган өлешләрен юлларны кардан чистартуга җибәрергә)

2) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (су белән тәэмин итү системасы өчен бикләр сатып алу).

3) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Беларус 82.1 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, (запас частьләр, дизель ягулыгы сатып алу, тракторга асылмалы җайланмалар сатып алу), үлән чабу, агачлар кисү).

4) Урамнарны яктырту җайланмасы (Бәзәкә авылында яктырткычлар сатып алу). Бәзәкә авылында урамнарны яктырту җайланмасы).

5) Янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын буяу өчен буяу сатып алу).

6) Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (Бәзәкә авылында рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча хезмәт күрсәтүләр)

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Бәзәкә авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов